КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 22 март г.Казань № 211

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Югары һәм урта һөнәри белемле кадрлар әзерләүгә һәм кадрларны тизләтеп әзерләүгә Татарстан Республикасы дәүләт заказын формалаштыруга һәм кадрлар әзерләүгә Татарстан Республикасы икътисады ихтыяҗын фаразлау регламентын раслау турында» 2014 ел, 31 март, 208 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Президентының «2018 – 2019 елларга Россия Федерациясе субъектларында инвестиция климаты торышының илкүләм рейтингы күрсәткечләре нигезендә Татарстан Республикасында инвестиция климатын яхшырту буенча чаралар планын («юл картасын») раслау турында» 2018 ел, 18 декабрь, 425 нче боерыгын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Югары һәм урта һөнәри белемле кадрлар әзерләүгә һәм кадрларны тизләтеп әзерләүгә Татарстан Республикасы дәүләт заказын формалаштыруга һәм кадрлар әзерләүгә Татарстан Республикасы икътисады ихтыяҗын фаразлау регламентын раслау турында» 2014 ел, 31 март, 208 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 15 февраль, 81 нче; 2017 ел, 21 март, 173 нче; 2017 ел, 16 август, 585 нче; 2017 ел, 1 сентябрь, 626 нчы; 2017 ел, 15 ноябрь, 877 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

$6^1$ нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$6^1$. Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгына, Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына, Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгына, Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгына, Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасының Спорт министрлыгына (алга таба – ведомство буйсынуында мәгариф оешмалары булган тармак министрлыклары):

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт аккредитациясе булган белем бирү оешмалары арасында Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән урта һөнәр белеме һәм югары белем бирә торган белем бирү программалары буенча укыту өчен һөнәрләр, белгечлекләр һәм әзерлек юнәлешләре буенча гражданнарны кабул итүнең контроль саннарын бүлүгә конкурс үткәрү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 5 ноябрь, 845 нче карары белән расланган Дәүләт аккредитациясе булган белем бирү оешмалары арасында Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән урта һөнәр белеме һәм югары белем бирә торган белем бирү программалары буенча укыту өчен һөнәрләр, белгечлекләр һәм әзерлек юнәлешләре буенча гражданнарны кабул итүнең контроль саннарын бүлүгә конкурс үткәрү тәртибенең (алга таба – Тәртип) 5 нче пункт нигезендә планлаштырыла торган елга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән урта һөнәри белем бирү һөнәрләре, белгечлекләре һәм (яки) белгечлекләрнең эреләтелгән төркемнәре, югары белем бирү белгечлекләре һәм әзерлек юнәлешләре һәм (яки) белгечлекләрнең һәм әзерлек юнәлешләренең эреләтелгән төркемнәре буенча укыту өчен кабул итүнең контроль саннары күләмнәрен формалаштырганда, югары һәм урта һөнәри белемле кадрлар әзерләүгә Татарстан Республикасы дәүләт заказына һәм кадрларны тизләтеп әзерләүгә дәүләт заказына (алга таба – Дәүләт заказы) кертелгән һөнәрләр, белгечлекләр, әзерлек юнәлешләре, белгечлекләрнең һәм әзерлек юнәлешләренең эреләтелгән төркемнәре буенча укытуга кабул итүнең контроль саннары күләмнәрен билгеләргә;

планлаштырыла торган елга урта һөнәри һәм югары белем бирүне оештыру чараларын тормышка ашыруга күздә тотылган Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән финанслауның билгеләнгән күләмнәре чикләрендә урта һөнәри һәм югары белем бирү һөнәрләренең, белгечлекләренең һәм әзерлек юнәлешләренең эреләтелгән төркемнәре буенча укытуга кабул итүнең контроль саннары күләмнәрен билгеләүне гамәлгә ашырырга;

«Инженерлык эше, технологияләр һәм техник фәннәр», «Авыл хуҗалыгы һәм авыл хуҗалыгы фәннәре» дигән урта һөнәри һәм югары белем бирү һөнәрләренең, белгечлекләренең һәм әзерлек юнәлешләренең эреләтелгән төркемнәре буенча укытуга кабул итүнең контроль саннары күләмнәрен билгеләгәндә кабул итүнең контроль саннары күләмнәренең әлеге һөнәрләр, белгечлекләр һәм әзерлек юнәлешләре төркемнәре буенча Дәүләт заказы күләмнәреннән 30 процентка артып китүен булдырмаска;

«Математика фәннәре һәм табигый фәннәр», «Сәламәтлек саклау һәм медицина фәннәре», «Җәмгыять турында фәннәр», «Мәгариф һәм педагогика фәннәре», «Гуманитар фәннәр», «Сәнгать һәм мәдәният» дигән урта һөнәри һәм

югары белем бирү һөнәрләренең, белгечлекләренең һәм әзерлек юнәлешләренең эреләтелгән төркемнәре буенча укытуга кабул итүнең контроль саннары күләмнәрен билгеләгәндә кабул итүнең контроль саннары күләмнәренең әлеге һөнәрләр, белгечлекләр һәм әзерлек юнәлешләре төркемнәре буенча Дәүләт заказы күләмнәреннән 15 процентка артып китүен булдырмаска.»;

түбәндәге эчтәлекле $6^2$ нче пункт өстәргә:

«$6^2$. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына үз эшчәнлеген Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыручы дәүләт аккредитациясе булган белем бирү оешмалары арасында конкурс үткәрүне оештырганда Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән урта һөнәр белеме һәм югары белем бирә торган белем бирү программалары буенча укыту өчен һөнәрләр, белгечлекләр һәм әзерлек юнәлешләре буенча гражданнарны кабул итүнең контроль саннарын бүлү өчен урта һөнәри һәм югары белем бирү һөнәрләре, белгечлекләре һәм әзерлек юнәлешләре буенча укыту өчен кабул итүнең контроль саннарын ведомство буйсынуында мәгариф оешмалары булган тармак министрлыкларыннан Тәртип нигезендә бу карарның $6^1$ нче пункты белән билгеләнә торган күләмнәрдә алырга.»;

әлеге карар белән расланган Югары һәм урта һөнәри белемле кадрлар әзерләүгә һәм кадрларны тизләтеп әзерләүгә Татарстан Республикасы дәүләт заказын формалаштыруга һәм кадрлар әзерләүгә Татарстан Республикасы икътисады ихтыяҗын фаразлау регламентында:

3 нче пунктта:

«Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасының Спорт министрлыгы, Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре министрлыгы» сүзләренә алыштырырга;

«Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына» сүзләреннән соң «, Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау буенча дәүләт комитетына,» сүзләрен өстәргә;

11 нче пунктның дүртенче абзацында «Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасының Спорт министрлыгы, Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре министрлыгы» сүзләренә алыштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин